| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2023 елның 19 октябреннән №39

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Җөэмин-Каратай авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 декабрендәге 34 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүе турында, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирүе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 декабрендәге 334 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүе турында, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирүе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

16 пунктның 2 абзацында:

«яисә аларның тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләрен бирү» сүзләрен «үзләренең чыгымнары турында белешмәләр, алдан ук тулы булмаган белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, йә күрәләтә дөрес булмаган белешмәләр бирү» сүзләренә алмаштырырга;

«йә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында алдан ук тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшырмау яисә тапшырмау» сүзләрен «яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләрне тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр тапшыру, йә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылында урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Ә.А.Ханнанова